ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 октября 2024 г. № 7084

Башкарма комитетның 2022 елның 9 декабрендәге 6986 номерлы Карары белән расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы Карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 9 декабрендәге 6986 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 июнендәге 5185 номерлы Карары редакциясендә) расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.17 пункт өстәргә:

«2.17. Муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда
күрсәтү очраклары һәм тәртибе

Муниципаль хезмәт 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясында каралган алдан (проактив) режимда күрсәтелми.»;

2) 3.5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.7. Комиссия секретаре комиссия карарын бәяләмә (административ регламентка 6 нчы кушымта) рәвешендә өч нөсхәдә рәсмиләштерә һәм имзалау өчен комиссия әгъзаларына тапшыра.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып имзалау өчен тапшырылган бәяләмә тора.»;

3) 3.5.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.11. Комиссия секретаре расланган бәяләмәне гариза бирүчегә һәм Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә (берешәр нөсхә) тапшыра. Бер нөсхә комиссия тарафыннан формалаштырылган делода кала.

Административ регламентның 3.5.9 – 3.5.11 пунктларында билгеләнә торган административ процедуралар 3.5.8 пунктчада каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап өч эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып расланган һәм гариза бирүчегә җибәрелгән бәяләмә тора.»;

4) кушымтада каралганча 6 нчы кушымта өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2024 елның 28 октябрендәге
7084 номерлы карарына
кушымта

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

(форма)

Бүлмәнең (күпфатирлы йортның) Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында
БӘЯЛӘМӘ

№ ____________________________ ______________________________
(дата)

______________________________________________________________________
(бүлмәнең урнашу урыны, шул исәптән торак пунктның һәм урамның исемнәре, йортның һәм фатирның номерлары)

______________________________________________________________________
(кем тарафыннан билгеләнгән, федераль башкарма хакимият органының,

______________________________________________________________________
Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органының, җирле үзидарә органының исеме, комиссия чакыру турында карарның датасы, номеры)

тарафыннан билгеләнгән ведомствоара комиссия
рәис ________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

______________________________________________________________________

һәм комиссия әгъзалары__________________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар__________________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

һәм чакырыдган торак милекчесе яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат катнашында

______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм эш урыны)

документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча

___

(документлар исемлеге күрсәтелә)

___

һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия тарафыннан төзелгән акт нигезендә

___

(тикшерү актыннан алынган бәяләмә күрсәтелә (тикшерү үткәрелгән очракта)

___

яки ведомствоара комиссия карары нигезендә тикшерү үткәрелмәү күрсәтелә)

___

___

___

түбәндәгеләр турында карар кабул итте

___

бүлмәнең (күпфатирлы йортның)

___

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча

___

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында

___

ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән бәяләмәнең нигезләре китерелә)

Бәяләмәгә кушымта:
а) карап тикшерелгән документлар исемлеге;
б) бүлмәне тикшерү акты (тикшерү үткәрелгән очракта);
в) ведомствоара комиссия тарафыннан соратып алынган башка материаллар исемлеге;
г) ведомствоара комиссия әгъзаларының аерым фикере:

___.

Ведомствара комиссия рәисе

| | |
|---|---|
| ___ | ___ |
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Ведомствара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| ___ | ___ |
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |
| ___ | ___ |
| (имза) | (Ф.И.А.) |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова